РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.02.2018 № 155-п

2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик
яклау буенча тотылган чыгымнарны каплауга
авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә
субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Авыл хуҗалыгы культураларының уңышын һәм сыйфатын арттыру максатында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау буенча тотылган чыгымнарны каплауга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән субсидияләр бирү максатларында Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба - ФБП) субсидияләр бирү турында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында https://saby.tatarstan.ru адресы буенча хәбәр урнаштырырга.
3. 3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 12 февралендәге 155-п номерлы карары белән РАСЛАНГАН

**2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау чыгымнарын каплауга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибе**

**1. Субсидия бирү турында гомуми нигезләмәләр**

**1.1.** 2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау буенча 2017 елда тотылган чыгымнарны каплауга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибе 2017 елда гамәлгә кертелгән үсемлекләрне биологик һәм химик яклау чыгымнарын каплауга җирле бюджет чаралары исәбеннән субсидияләр бирү процедурасын (алга таба - Субсидия) билгели.

**1.2.** Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә милекнең барлык рәвешләрендәге (алга таба - авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) субсидияләр бирүнең максаты - 2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау буенча тотылган чыгымнарны каплау һәм авыл хуҗалыгы культураларының уңдырышлылыгын һәм сыйфатын арттыру.

**1.3.** 2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау буенча тотылган чыгымнарны каплауга җибәрелә торган җирле бюджет чараларын баш бүлүче булып Саба муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тора

**1.4.** Субсидия бирү Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы "2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты турында" Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга гамәлгә ашырыла.

**1.5.** Субсидия бирү турында хәбәр, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында, субсидия бирү турында гаризалар кабул итү тәмамланган датага кимендә унбиш көн кала урнаштырыла.

**1.6.** 2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау буенча тотылган чыгымнарны каплауга субсидияләр (алга таба - субсидияләр) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы культуралары мәйданнары булган үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына бирелә.

**1.7.** Субсидияләр 2017 елда сатып алынган биологик һәм химик яклау чараларының бәясенең 100% күләмендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә НДС һәм транспорт чыгымнарын исәпкә алмыйча бирелә.

**1.8.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - башкарма комитет) субсидияләрне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Саба районы буенча департаменты территориаль бүлегендә ачылган шәхси счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең исәп-хисап счетларына күчерә.

## 2. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

**2.1.** Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре субсидия алу өчен Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба - Палата) түбәндәге документларны тапшыралар:

– - юридик затны (шәхси эшмәкәрне) дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен;

– - Устав күчермәсе (юридик затлар өчен) һәм аның карап чыгу өчен төп нөсхәсе , шулай ук (булса) аңа кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр күчермәләре (күзәтү өчен төп нөсхә);

– - гамәлгә кую шартнамәсенең яисә затны гамәлгә кую турында вәкаләтле органның карары күчермәсен һәм аның төп нөсхәсен (карау өчен төп нөсхәсен);

– - салым исәбенә кую турында таныклык күчермәсен;

– - заем алучы исеменнән эш башкару өчен затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

– 2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау чараларын китерү шартнамәләре;

– 2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау чараларын кертү буенча хезмәт күрсәтүләргә шартнамәләр;

– «2017 ел уңышы өчен чәчү йомгаклары турында белешмәләр» 4-СХ яисә 1-фермер рәвешләре буенча хисаплар (алга таба - статистик хисаплар);

– счетлар-фактуралар, товар-транспорт накладнойлары, түләү йөкләмәләре, алар түләү фактларын, башкарылган эшләр актларын раслый;

– үзара йөкләмәләрне исәпкә алу турында килешү;

– 2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау чыгымнарын каплауга белешмә-исәп;

– 2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау буенча тотылган чыгымнарны каплауга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан акчалар авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан алынмавы турында белешмә.

**2.2.** ФБП әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның дөреслеген тикшерә һәм субсидия бирү турындагы мәсьәләне карау өчен Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 16 ноябрендәге 1441-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алу һәм җиңүчеләрне билгеләү өчен гаризаларны карау һәм бәяләү буенча комиссиясенә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең гаризаларын кушымта итеп бирелә торган документлар белән тапшыра.

**2.3.** Документлар һәм материаллар Палатадан алынганнан соң комиссия аларны карый һәм субсидия бирү мөмкинлеге турында карар чыгара, яки,сәбәпләрне күрсәтеп, субсидия бирүдән баш тарта.

**2.4.** Заемчыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

– - заемчы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1, 2.6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

– субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

**2.5.** Комиссиянең уңай карары булганда, Башкарма комитет субсидия бирү турында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2015 елның 22 июлендәге 1001-п номерлы карары белән расланган Административ регламентка 2 нче кушымта нигезендә килешү төзи һәм субсидияне

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Саба районы буенча территориаль бүлегендә ачылган үзенең шәхси счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең исәп-хисап счетларына күчерә.

Субсидия бирү турында шартнамә 1 елга гамәлдә булу срогы белән төзелә.

Субсидияләр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Һитәкчесенең 2015 елның 22 июлендәге 1001-п номерлы карары белән расланган Административ регламентта билгеләнгән срокларда күчерелә, әмма документларны карау нәтиҗәләре буенча баш бүлүче белән килешүне төзегәннән соң унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

**2.6.** Субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айның беренче көненә субсидия алуга дәгъва кылучылар:

– - үз хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү буенча бурыч булырга тиеш түгел;

– - бюджет кредитлары буенча бурыч булырга тиеш түгел.

– соңгы хисап чорында бухгалтерлык хисабы мәгълүматлары буенча дәгъвачы активларының баланс бәясенең егерме биш процентыннан артыграк булган соңгы хисап чорында теләсә кайсы дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына исәпләнгән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаска тиеш;

– субсидия алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидияләр алучылар - шәхси эшмәкәрләр шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлекне туктатырга тиеш түгел;

– - оешма устав (җыелма) капиталында салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) юридик затларга карата финанс операцияләре башкарганда мәгълүмат ачуны һәм тапшыруны күздә тотмаган дәүләтләрнең һәм территорияләрнең (офшор зоналарының) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлегенә кертелгән дәүләттә яки территориядә теркәлгән чит ил юридик затларының катнашу өлеше җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмый торган чит ил юридик заты, шулай ук Россия юридик заты булып тормаса;

– хокукый акт нигезендә субсидия бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан акчаларны, башка норматив хокукый актлар яисә 2017 елда үсемлекләрне биологик һәм химик яклау буенча тотылган чыгымнарны каплауга муниципаль хокукый актлар нигезендә алмаска тиеш.

## 3. Субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп тору һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны гамәлгә ашыру турындагы таләпләр.

**3.1.** Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны тикшереп торуны Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы гамәлгә ашыра.

**3.2.** Саба муниципаль районының контроль-хисап палатасы субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерә.

**3.3.** Субсидия алучы тарафыннан бюджет акчаларын алучы буларак баш күрсәтмә бирүче һәм муниципаль финанс тикшерүенең вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Контроль-хисап палатасы тарафыннан уздырылган тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган очракта, бирелгән субсидия субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш

**3.4.** Бирелгән субсидияләр субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактларын ачыклау буенча Башкарма комитетның тиешле

таләпләрен алган көннән алып 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

**3.5.** Күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемнә ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

**3.6.** Бирелә торган документларның дөреслеге, бюджет акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану, коррупциягә каршы законнарны үтәү өчен җаваплылык субсидия алучыларга йөкләнә. Хокук бозучыларга карата гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык чаралары кулланыла.